**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

# КАРАРЫ

**Утыз тугызынчы утырыш**

**№ 130**

**«21» май 2024 ел** **Иске Җөри авылы**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 10.12.2014 ел № 129-1 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 06 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 10.12.2014 ел № 129-1 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә:

А) 5.1 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне минималь рөхсәт ителгән бәядән сату;»;

Б) 5.5 пунктта «бәяләрне игълан итмичә мөлкәт» сүзләрен «минималь рөхсәт ителгән бәя буенча мөлкәт» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мараков